ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЗАЙ-КАРАТАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЗӘЙ-КАРАТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 29 октябре № 34

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Административ регламентларын гамәлдән чыгару турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск муниципаль районы « Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гамәлдән чыгарырга:

- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендәге 8 номерлы карары карары белән расланган документларның һәм аларның күчермәләренең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендә кабул ителгән 9 номерлы карары белән расланган васыятьнамә таныклыгы яки ышанычнамә таныклыгы-нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламенты

- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендә кабул ителгән 3 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент

- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендә кабул ителгән 3 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, кронировкалауга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент

2. Әлеге карарны Зәй-Каратай авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы М.И.Идиятова